МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**11.11.2016** г.Казань **№ 01-02/288**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау турында

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 112 номерлы Указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турындагы Нигезләмәне раслау турында» ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре турында» ПУ-1192 Указы нигезендә, **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы әлеге нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү

турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 17 февралендәге К-26/03-03 номерлы боерык;

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 18 апрелендәге К-53/03-03 номерлы боерык.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Заһидуллин

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
11.11.2016 № 01-02/288
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләти граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү буенча Конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, эш сроклары һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы дәүләти граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә керүгә булган тигез хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә булган хокукларын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында конкурс 2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 112 номерлы Указы, 2003 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 14 мартындагы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтенә кадрлар резервы турындагы Нигезләмәне раслау турында» ПУ-127 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре турында» ПУ-1192 Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс дәүләт граждан хезмәте (алга таба – граждан хезмәте) вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәләрен бәяләүдән, аларның

граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүләрен ачыклаудан гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта вакантлы урынны биләүгә конкурс Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – министр) карары белән әлеге вазыйфаны биләү Федераль закон нигезендә конкурс нигезендә башкарыла торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булган чакта игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә белгечләргә фаразланган ихтыяҗны һәм Министрлыкның булган кадрлар резервын ел саен уздырыла торган бәяләү нәтиҗәләре буенча кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.5. Министрлыкта түбәндәге очракларда вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс үткәрелми:

граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләре вазыйфаларына билгеләнгән вәкаләтләр чорына билгеләп куйганда;

сроклы хезмәт контракты төзегәндә;

граждан хезмәткәрен Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешендә, 31 статьясындагы 1 өлешендә һәм 60.1 статьяның 9 өлешләрендә каралган очракларда граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләп куйганда;

граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.6. Министрлыкта вакантлы урыннарга конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

вазыйфаи бурычларны үтәү Министрлык боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге нигезендә дәүләт сере булып торган мәгълүматлардан файдалану белән бәйле булган граждан хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

министр карары буенча граждан хезмәтенең кече вазыйфалары төркеменә керүче граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә дәүләт граждан хезмәтенә бертигез дәрәҗәдә керү мөмкинлегенә конституциячел хокукларын тәэмин итү, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм конкурста катнашуга кертелүче кандидатлар арасыннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен иң кулай кандидатларны сайлап алу;

граждан хезмәте вазыйфаларын башкару өчен Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.8. Конкурслар үткәрүдә хәл ителә торган бурычлар:

конкурс биремнәрен һәм процедураларын үтәүдә барлык кандидатларга тигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән конкурста катнашучылар арасыннан гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфалары (кадрлар резервына кертелү) таләпләренә туры килүче затларны билгеләү.

## II. Конкурс комиссиясен булдыру һәм аның эш тәртибе

2.1. Министрлыкта конкурс үткәрү өчен министр боерыгы белән Министрлык аппараты өчен һәм Татарстан Республикасының җәмәгать судьялары аппаратлары өчен даими нигездә эшли торган конкурс комиссияләре төзелә. Комиссия составына кертелгән урындагы затларның персональ составы үзгәргән чакта министр боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссиянең эшен тәэмин итә (гаризалар кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) министр тарафыннан Министр урынбасарлары, кадрлар бүлеге, юридик бүлек башлыгы, Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган структур бүлекчәсе җитәкчесе яисә җитәкче урынбасары, Министрлыкның югары квалификацияле хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департаменты вәкиле, шулай ук бәйсез экспертлар буларак Министр үтенече буенча Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт хезмәткәрләре эшләре буенча департаменты тарафыннан (әлеге экспертларның персональ белешмәләре күрсәтелми) чакырылган фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмалар вәкилләре – дәүләт хезмәте белгечләре кертелә.

Конкурс комиссиясе составына министр һәм (яки) ул вәкаләтләр биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлегеннән, норматив хокукый актларны теркәү һәм министрлык эшчәнлеген хокукый тәэмин итү бүлегеннән) һәм Министрлыкның граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар

резервына кертелүгә) конкурс уздырыла торган структур подразделениесеннән граждан хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы кадрлар һәм дәүләт хезмәте департаменты вәкиле, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук граждан хезмәте белән бәйле сораулар буенча белгечләр – персональ мәгълүматлары күрсәтелмәгән бәйсез экспертлар сыйфатында министр үтенече буенча Департамент тарафыннан чакырылган фәнни һәм белем бирү учреждениеләре, башка оешма вәкилләре керә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санының дүрттән береннән дә ким булмаска тиеш.

2.5. Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалану вазыйфаи бурычларына кертелгән граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү өчен конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнар нигезләмәләрен истә тотып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс карарларын кабул итүгә йогынты ясарлык мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу куркынычы калмаслык итеп төзелергә тиеш.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә) кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса тулы хокуклы дип санала. Конкурс комиссиясе утырышын граждан хезмәте вазыйфаларын били торган әгъзалар катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе карары кандидат үзе булмаганда кабул ителә.

2.9. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән аның утырышта катнашкан әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар саны тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

2.10. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре) рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана торган конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

2.11. Конкурсны оештыру, аны үткәрү, конкурс комиссиясенең эше Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан башкарыла.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга Министрлыкта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылучы кандидатларга карата тиешле таләпләргә туры килеп, әлеге Нигезләмәнең 3.4 пунктында

күрсәтелгән документларны әлеге Нигезләмәнең 3.7 пунктында билгеләнгән срокта тапшырган гражданнар кертелә.

3.2. Гражданин (граждан хезмәткәре), граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте вазыйфаларына) квалификация таләпләренә җавап бирмәү сәбәпле, шулай ук Федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидатларга булган таләпләр Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданины Министрыкка тапшыра:

шәхси гаризасын (әлеге Нигезләмәгә кушымта);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган формадагы үз кулы белән тутырган һәм имзаланган, фоторгафияләр беркетелгән (4х6 см.) анкетасын;

паспортының яисә аны алыштыручы документның күчермәсен (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

кирәкле һөнәри белемен, эш стажын һәм квалификациясен раслаучы документлар:

хезмәт кенәгәсенең нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче мәртәбә башкарыла торган очраклардан гайре) яисә гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы бүтән документлар;

белеме һәм квалификациясе турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча – өстәмә һөнәри белем алу яки белем күтәрү, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелү турындагы документларның нотариаль яки эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган күчермәләре;

гражданның граждан хезмәтенә керергә яисә аны узарга каршы килерлек авыруы булмавы турында документ (Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 14.12.2009 № 984н боерыгы белән расланган 001-ГС/у формасы);

Федераль закон, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты указлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган бүтән документлар.

3.5. Министрлыкта граждан хезмәте вазыйфасын биләүче, Министрлыкта конкурста катнашырга теләк булдергән очракта, министр исеменә гаиза яза.

Бүтән дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашуга теләк белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка шәхси гаризасын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган формадагы үз кулы белән тутырган һәм имзаланган, граждан хезмәткәре граждан хезмәте вазыйфасын башкара торган дәүләт органының кадрлар

хезмәте тарафыннан расланган, фотогафияләр беркетелгән (4х6 см.) анкетасын тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) рөхсәте белән, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) дәгъва итүче граждан хезмәтенең вәкаләтле вазыйфаларын башкару дәүләт яисә закон тарафыннан саклана торган башка серне тәшкил итүче мәгълүматлардан файдалануга бәйле булса, аңа карата мондый мәгълүматларны рөхсәт итүне рәсмиләштерү процедурасы үткәрелә.

Гражданин тарафыннан министр исеменә тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелергә тиеш.

3.7. Конкурста катнашу өчен документлар кандидатлар тарафыннан Министрлыкка “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Министрлыкның рәсми сайтында конкурс уздыру турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән 21 көн эчендә тапшырыла.

3.8. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданиннан аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Документларны ихтирамга лаеклы сәбәп аркасында вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру очрагында министр документларны кабул итү срогын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурс уздыру методикасы

4.1. Конкурс үткәрүдә кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган ысулларына нигезләнгән конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары Министрлыкның граждан хезмәте вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурс уздырыла торган вазыйфаларның төркеменә һәм категорияләренә бәйле рәвештә конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары һәм алымнар үзгәрергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан үтәлгән конкурс биремнәре һәм конкурс процедураларын үтәү нәтиҗәләре нигезендә хәл ителә.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.4.1. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге оештыра:

конкурс уздыру турында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында

Министрлыкның рәсми сайтында конкурс уздыру турында мәгълүмат әзерләп урнаштыруны. Әлеге хәбәр үз эченә ала: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасының (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте вазыйфасының) атамасы, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы кандидатларга карата куела торган таләпләр, граждан хезмәтен үтү шартлары, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва белдерүче кандидатлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырыла торган документларны кабул итү урыны һәм вакыты, әлеге документларны кабул итүне тәгәлләү срогы, конкурсны үткәрүнең якынча датасы, аны үткәрү урыны һәм тәртибе, шулай ук башка мәгълүмати материалларны;

кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны тикшерүне;

гражданинның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә (профессиональ белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте стажы (башка төрдәге дәүләт хезмәте) яки белгечлеге буенча эш стажы (тәҗрибәсе), әзерлек юнәлеше, профессиональ белемнәре һәм вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле күнекмәләре) җавап бирүләрен.

4.4.2. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтенә керүенә каршылык тудыра торган сәбәпләр чыккан очракта, ул кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге тарафыннан конкурста катнашуга кертелмәү сәбәпләре турында язма рәвештә искәртелә.

4.4.3. Конкурста катнашуга кертелмәгән вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы бу карарга Россия Федерациясе законы нигезендә шикаять белдерүгә хокуклы.

4.4.4. Конкурсның беренче этабын тәгәлләү шарты булып, кандидатларны алга таба сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итәр өчен, Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы урынына (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте вазыйфасына) билгеләнгән таләпләргә туры килгән икедән ким булмаган кандидатларның булуы кирәк.

Кандидатлар ачыкланмаган очракта яки билгеләнгән таләпләргә туры килгән кандидат берәү генә булганда конкурс узмаган булып санала. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурсның кандидатларның тиешле күләмдә булмаулары нәтиҗәсендә узмаган булып танылуы турында язмача рәвештә хәбәр ителә.

4.4.5. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач министр конкурсның икенче этабын уздыру вакыты, урыны һәм көне турында карар кабул итә.

Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге конкурсның икенче этабы башланырга 15 көннән дә соңга калмыйча конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга конкурс үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында гамәлгә ашырыла:

конкурс комиссиясенең кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләве;

конкурс комиссиясенең Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итүе.

4.4.7. Конкурсны уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны белемнәре, граждан яки башка дәүләт хезмәтендә булулары, башка төрле хезмәт эшчәнлеге башкарулары турында алар тарафыннан бирелгән документлар, шулай ук кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләүнең Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган алымнарын кулланып тест узу һәм башка конкурс процедураларын узу, шул исәптән кандидатлар Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте вазыйфаларына) дәгъва итә торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле сораулар буенча тест узу һәм индивидуаль әңгәмә нигезләре буенча бәяли.

4.4.8. Кандидатларга Министрлыкта граждан хезмәтенә вакантлы вазыйфаны (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте вазыйфаларын) биләүгә тест уздыру Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарга тест уздыруның Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 1 ноябрендәге 1 номерлы карары белән расланган методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тестны узган кандидатлар белән индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан уздырыла.

Индивидуаль әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган кандидатларның булачак профессиональ эшчәнлекләренә караган сорауларга телдән җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе граждан хезмәте вазыйфасына квалификация таләпләреннән һәм бу вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Ресубликасының дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарының башка нигезләмәләреннән чыгып кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе булып һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.6. Конкурска нәтиҗәләр ясау һәм гражданинны Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләүгә (кадрлар резервына кертүгә) нигез булып кандидатлар җыйган тавышлар саны, кандидатлар дәгъва кыла торган вазыйфаның структур бүлекчәсе җитәкчесенең фикере тора.

4.7. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә конкурс игълан ителгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертелүгә граждан хезмәте

вазыйфаларына) кирәкле барлык таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаганда, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү турында карар кабул итүгә яки яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертүгә хокуклы.

4.8. Граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс җиңүчесен граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына билгеләү турында министр указы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма профессиональ һәм шәхси сыйфатлары ягыннан югары бәягә лаек булган гражданинны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында рекомендация характерындагы карар кабул итәргә дә мөмкин.

Кандидат ризалыгы белән аны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы караган шул ук төркемдәге граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы бирелә.

Конкурс җиңүчесен - граждан хезмәткәрен (гражданинны) кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.9. Кандидатларга конкурс нәтиҗәләре турында конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә язмача рәвештә хәбәр юллана. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә Министрлыкның рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4.10. Кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять белдерергә хокуклы.

4.11. Конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъва кылучыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланган көннән соң өч ел эчендә аларның язмача гаризалары нигезендә кире кайтарылырга мөмкин. Шушы срок узганчы документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарыла.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле матди чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану чыгымнары һәм башкалар) кандидатларның үз акчалары исәбеннән башкарыла.

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы
дәүләт граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфаларына
(кадрлар резервына кертелүгә)
конкурс үткәрү турындагы
Нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министры
___________________________________
(министрның фамилиясе, инициаллары)
___________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме)
___________________________________
(гариза бирү вакытына яшәү урыны адресы; эш урыны,
___________________________________
биләгән вазыйфасы)
___________________________________
(кәрәзле телефон номеры, эл.почта)

Гариза

Мине Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм:____________________________________________________
(вазыйфаның һәм бүлекчәнең атамасы)
________________________________________________________________________

2004 елның 27 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 79-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 16 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте турында» 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының 2005 елның 1 февралендәге «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс турында» 112 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (кадрлар резервына кертелүгә) конкурс үткәрү турындагы Нигезләмә, шул исәптән вакантлы вазыйфага дәгъва итүчедән сорала торган квалификацион таләпләр белән таныштым. 2006 елның 27 июлендәге

«Персональ мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә персональ мәгълүматларны тикшертүгә ризалык бирәм.

Конкурс уздырылу көне һәм урыны турында E-mail аша яки күрсәтелгән мобиль телефон номерына СМС – хәбәр җибәреп хәбәр итү белән килешәм.

Гаризага кушып бирәм:

______________________________________________________________________________

(кушып бирелә торган документларны санап чыгарга)

____________________ ____________________ ____________________

(дата) (имза) (имзаның расшифровкасы)